**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 9 ноябрендәге 4692 номерлы карары**

**Хәрәкәттәге составны (автобусларны) финанс белән бәйле арендалау (лизинг) килешүләре нигезендә лизинг түләүләрен башкаруга чыгымнарны (чыгымнарның бер өлешен) финанс белән тәэмин итү өчен шәһәр автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашыра торган юридик затларга һәм (яисә) шәхси эшмәкәрләргә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар җитештерүче, эшләр башкаручы, хезмәтләр күрсәтүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр формасында грантлар бирүне һәм күрсәтелгән субсидияләр, шул исәптән субсидияләр формасындагы грантлар алучыларны сайлап алуны уздыруны җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында»гы карары, Казан шәһәре Думасының 2023 елның 14 декабрендәге 2-27 номерлы «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында»гы карары (аңа Казан шәһәре Думасының 2024 елның 28 февралендәге 7-28 номерлы, 2024 елның 26 апрелендәге 4-29 номерлы, 2024 елның 26 июнендәге 3-30 номерлы, 2024 елның 28 августындагы 8-32 номерлы, 2024 елның 1 октябрендәге 2-33 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) нигезендә **карар бирәм**:

1. Расларга:

1.1. әлеге карарга 1 номерлы кушымта нигезендә Хәрәкәттәге составны (автобусларны) финанс белән бәйле арендалау (лизинг) килешүләре нигезендә лизинг түләүләрен башкаруга чыгымнарны (чыгымнарның бер өлешен) финанс белән тәэмин итү өчен шәһәр автомобиль транспортында даими рәвештә

пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашыра торган юридик затларга һәм (яисә) шәхси эшмәкәрләргә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

1.2. әлеге карарга 2 номерлы кушымта нигезендә Хәрәкәттәге составны (автобусларны) финанс белән бәйле арендалау (лизинг) килешүләре нигезендә лизинг түләүләрен башкаруга чыгымнарны (чыгымнарның бер өлешен) финанс белән тәэмин итү өчен шәһәр автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашыра торган юридик затларга һәм (яисә) шәхси эшмәкәрләргә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү комиссиясе турында нигезләмәне;

1.3. әлеге карарга 3 номерлы кушымта нигезендә хәрәкәттәге составны (автобусларны) финанс белән бәйле арендалау (лизинг) килешүләре нигезендә лизинг түләүләрен башкаруга чыгымнарны (чыгымнарның бер өлешен) финанс белән тәэмин итү өчен шәһәр автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашыра торган юридик затларга һәм (яисә) шәхси эшмәкәрләргә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү комиссиясе составын.

2. Хәрәкәттәге составны (автобусларны) финанс белән бәйле арендалау (лизинг) килешүләре нигезендә лизинг түләүләрен башкаруга чыгымнарны (чыгымнарның бер өлешен) финанс белән тәэмин итү өчен шәһәр автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашыра торган юридик затларга һәм (яисә) шәхси эшмәкәрләргә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү буенча Казан шәһәре Башкарма комитетының вәкаләтле органы итеп Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетын билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 9 ноябрендәге
4692 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Хәрәкәттәге составны (автобусларны) финанс белән бәйле арендалау (лизинг) килешүләре нигезендә лизинг түләүләрен башкаруга чыгымнарны (чыгымнарның бер өлешен) финанс белән тәэмин итү өчен шәһәр автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашыра торган юридик затларга һәм (яисә) шәхси эшмәкәрләргә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе**

1. Әлеге тәртип хәрәкәттәге составны (автобусларны) финанс белән бәйле арендалау (лизинг) килешүләре нигезендә лизинг түләүләрен башкаруга чыгымнарны (чыгымнарның бер өлешен) финанс белән тәэмин итү өчен шәһәр автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашыра торган юридик затларга һәм (яисә) шәхси эшмәкәрләргә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү процедурасын билгели (алга таба – субсидияләр).

2. Хәрәкәттәге составны (автобусларны) финанс белән бәйле арендалау (лизинг) килешүләре нигезендә лизинг түләүләрен башкаруга чыгымнарны (чыгымнарның бер өлешен) финанс белән тәэмин итү максатыннан шәһәр автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашыра торган юридик затларга һәм (яисә) шәхси эшмәкәрләргә субсидияләр бирелә.

3. Субсидия бирү Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитеты (алга таба – Вәкаләтле орган) тарафыннан тиешле финанс елына һәм план чорына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында Казан шәһәре Думасы карарында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм әлеге тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга субсидияләр бирү өчен билгеләнгән тәртиптә бюджет чараларын алучы буларак Вәкаләтле органга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

4. Тиешле финанс елына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында каралган субсидияләр Вәкаләтле органның Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Казан шәһәре территориаль бүлекчәсендә ачылган шәхси счетында исәпкә алына.

5. Субсидия алучылар Хәрәкәттәге составны (автобусларны) финанс белән бәйле арендалау (лизинг) килешүләре нигезендә лизинг түләүләрен башкаруга чыгымнарны (чыгымнарның бер өлешен) финанс белән тәэмин итү өчен шәһәр автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашыра торган юридик затларга һәм (яисә) шәхси эшмәкәрләргә субсидияләр бирү комиссиясе (алга таба – Комиссия) тарафыннан сайлап алуда катнашучыларның сайлап алу категорияләренә, критерийларына туры килүеннән һәм гаризалар килү чиратыннан чыгып, юридик затлар һәм (яисә) шәхси эшмәкәрләр (алга таба – сайлап алуда катнашучылар) тарафыннан сайлап алуда катнашу өчен юлланган тәкъдимнәрне (гаризаларны) соратып алу юлы белән үткәрелә торган сайлап алу нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

6. Субсидия турындагы мәгълүматлар, бюджет турында закон (карар) (бюджет турында законга (карарга) үзгәрешләр кертү турында закон (карар)) кабул ителгән көннән соң килүче 15 эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) (бердәм портал бүлегендә) урнаштырыла;

7. Субсидия алучыларны сайлап алуны уздыру турында мәгълүмат, сайлап алуда катнашу өчен гаризалар кабул ителә башлау көненә кадәр 3 эш көненнән дә соңга калмыйча, Вәкаләтле орган тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (https://kzn.ru/meriya/ispolnitelnyy-komitet/komitet-po-transportu/konkursy/) (алга таба – рәсми портал) урнаштырыла.

8. Субсидия алучыларны сайлап алуны уздыру турындагы игъланда түбәндәге мәгълүмат күрсәтелергә тиеш:

- сайлап алуны уздыру вакыты, сайлап алуда катнашучыларның гаризаларын кабул итү башлану һәм тәмамлану көне һәм вакыты, шул ук вакытта гаризаларны кабул итү тәмамлану көне сайлап алуны уздыру турында игълан урнаштырылган көннән соң килгән биш календарь көннән дә иртәрәк була алмый;

- Вәкаләтле органның атамасы, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

- Вәкаләтле орган сайтының домен исеме һәм (яисә) челтәр адресы, һәм (яисә) сәхифәләр күрсәткечләре;

- әлеге тәртипнең 10 пункты һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеге нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләр;

- әлеге тәртипнең 9 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучылар туры килергә тиешле сайлап алу критерийлары;

- сайлап алуда катнашучылар тарафыннан гаризалар тапшыру тәртибе һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан әлеге тәртипнең 11, 13 пунктлары нигезендә тапшырыла торган гаризалар формасына һәм эчтәлегенә карата куелган таләпләр;

- гаризаларны кире алу тәртибе, гаризаларны кире кайтару, шул исәптән гаризаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгеләү тәртибе, гаризаларга үзгәрешләр кертү тәртибе;

- гаризаларны әлеге тәртипнең 14-16 пунктлары нигезендә карап тикшерү кагыйдәләре;

- гаризаларны кире кагу тәртибе, шулай ук аларны кире кагу нигезләре турында мәгълүмат;

- әлеге тәртипнең 12 пункты нигезендә эшләп бетерүгә гаризаларны кире кайтару тәртибе;

- сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны уздыру турындагы игълан нигезләмәләре буенча аңлатмалар бирү тәртибе, аңлатмалар бирүнең башлану һәм тәмамлану көне;

- сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) субсидия бирү турындагы килешүне (алга таба – килешү) имзаларга тиешле вакыт аралыгы;

- сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән баш тарткан (баш тартканнар) дип тану шартлары;

- бердәм порталда һәм рәсми порталда сайлап алуга нәтиҗә ясау беркетмәсен урнаштыру вакыты, ул сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килгән 14 календарь көннән дә соң була алмый;

- әлеге тәртипнең 31 пунктында билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе;

9. Сайлап алу критерийлары:

- сайлап алуда катнашучы Казан шәһәренең муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне башкаруга

муниципаль контрактлар нигезендә Казан шәһәрендә гомуми файдаланудагы транспортта пассажирлар йөртү буенча эшчәнлек алып барырга тиеш;

- сайлап алуда катнашучы «Дәүләт транспорт лизинг компаниясе» акционерлык җәмгыяте белән 2024 елның 1 июленнән алып һәм 2024 елның 31 декабренә кадәр төзелгән финанс белән бәйле арендалау (лизинг) килешүләренә ия.

10. Сайлап алуда катнашучы (субсидия алучы) әлеге тәртипнең 18 пунктында күрсәтелгән Комиссия утырышы көненә кадәр 5 эш көне эчендә түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

- чит ил юридик заты, шул исәптән Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган очракта) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда, офшор компанияләренең акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган сатуларда әйләнештә йөри торган гавами акционерлык җәмгыятьләре (шул исәптән халыкара компания статусы булган) капиталында турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук башка Россия юридик затлары капиталында офшор компанияләренең, әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып, турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

- экстремистик эшчәнлеккә яки терроризмга катнашлары турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

- БМО Уставының VII бүлеге, БМО Куркынычсызлык советы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кысаларында яки БМО Куркынычсызлык советы карарлары нигезендә махсус төзелгән оешмалар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән бәйле яисә массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

- әлеге тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге хокукый акты нигезендә, башка норматив хокукый актларына таянып, субсидия бирү планлаштырыла торган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге

бюджетыннан акчалар алмый;

- «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында»гы федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

- бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы юк яисә Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмый;

- юридик зат булып торган сайлап алуда катнашучы (субсидия алучы) үзгәртеп оештыру (субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) булып торган юридик затка башка юридик затны кушу формасында гамәлгә ашырылган үзгәртеп оештырудан тыш), ябылу процессында түгел, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, субсидия алучының (сайлап алуда катнашучының) эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмаган, ә шәхси эшмәкәр булып торган субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) шәхси эшмәкәр сыйфатында эшчәнлеген туктатмаган;

- дисквалификацияләнгән затлар реестрында юридик зат булып торган субсидия алучының (сайлап алуда катнашучының) дисквалификацияләнгән җитәкчесе, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер кеше башкара торган башкарма орган функциясен үтәүче зат яисә баш бухгалтеры (булган очракта) турында, шәхси эшмәкәр турында һәм субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) булган товар җитештерүче, эш башкаручы, хезмәт күрсәтүче физик зат турында белешмәләр юк;

- Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча түләү вакыты узган бурычы, шул исәптән Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты алдында акчалата йөкләмәләр буенча түләү вакыты узган (җайга салынмаган) башка бурычы юк;

11. Субсидия алуга сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучы Вәкаләтле органга түбәндәге документларны тапшыра:

- әлеге тәртипкә 1 номерлы кушымтада бирелгән форма буенча тутырылган, җитәкче яки башка вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган гариза;

- сайлап алуда катнашучының бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы булмавын яисә Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмавын раслый торган

документларның күчермәләре;

- сайлап алуда катнашучының хокукый актта билгеләнгән максатларга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге хокукый акты нигезендә, башка норматив хокукый актларына таянып, субсидия бирү планлаштырыла торган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан акчалар алмавын раслый торган документ;

- лицензияләнә торган эшчәнлек төрләре гариза бирүче тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырылганда, хуҗалык эшчәнлеген башкаруга лицензия күчермәсе;

- Казан шәһәренең муниципаль маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны башкаруга муниципаль контрактларның (килешүләрнең) булуын раслый торган документ;

- лизинг түләүләре графикларын кертеп, хәрәкәттәге составны финанс белән бәйле арендалау (лизинг) буенча «Дәүләт транспорт лизинг компаниясе» акционерлек җәмгыяте белән 2024 елның 1 июленнән алып 2024 елның 31 декабренә кадәр төзелгән килешүләрнең күчермәләре;

- әлеге тәртипкә 2 номерлы кушымтада бирелгән форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;

- субсидия күчерелә торган исәп-хисап счеты турында мәгълүмат.

Юридик зат өчен әлеге пунктта күрсәтелгән документларга өстәмә рәвештә түбәндәгеләр тапшырыла:

а) гамәлгә кую документларының һәм аларга кертелгән барлык үзгәрешләрнең күчермәләре;

б) җитәкче вәкаләтләрен раслый торган документлар.

Шәхси эшмәкәр өчен әлеге пунктта күрсәтелгән документларга өстәмә рәвештә шәхси эшмәкәр паспортының күчермәсе (беренче янәшә битләр һәм теркәлү тамгасы булган янәшә битләр), шәхси эшмәкәрне дәүләт теркәвенә алу турында таныклыкның күчермәсе (яисә Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестры теркәү кәгазенең күчермәсе) тапшырыла.

Тапшырылган документларның күчермәләре сайлап алуда катнашучы тарафыннан расланырга һәм мөһер белән (булган очракта) беркетелергә тиеш.

Бер катнашучы сайлап алуда катнашуга бер гариза бирергә хокуклы.

Гаризага кертелгән барлык документлар да төгәл бастырылган һәм барлык пунктлар буенча тутырылган булырга тиеш (мәгълүматлар булмаган очракта, сызык куела). Чистарту һәм төзәтүләр булырга тиеш түгел. Гаризаның барлык битләре (шул

исәптән теркәлә торган документлар) тегелгән, номерланган, субъектның имзасы һәм мөһере белән (булган очракта) беркетелгән булырга тиеш.

Сайлап алуда катнашучы тапшырылган гаризадагы һәм документлардагы мәгълүматның дөреслеге өчен җавап бирә.

Сайлап алуда катнашучы документларны кәгазь чыганакта тапшыра.

12. Гариза дәгъвачыга, гаризаларны карап тикшерү вакыты тәмамланганчыга кадәр 3 эш көненнән дә соңга калмыйча, эшләп бетерү өчен кайтарыла.

Гариза, аны кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, эшләп бетерүгә җибәрелә. Катнашучы гаризаны эшләп бетерергә юлланган көннән соң килүче көн эчендә гаризага үзгәрешләр кертергә һәм аны кабат бирергә хокуклы.

Өстәмә эшләп җибәрелгән гариза яңадан теркәлми һәм гариза бирү датасы булып дәгъвачының беренчел гаризасын имзалау көне санала.

Гаризалар документларда бетерелгән урыннар, өстәмә язулар булган очракта, шулай ук тәртипнең 11 пунктына туры килмәгән очракта, эшләп бетерүгә җибәрелә.

13. Сайлап алуда катнашучы Вәкаләтле орган адресына бер тәкъдим (гариза), шул исәптән сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелгән тәкъдим (гариза) турында мәгълүматны, сайлап алуда катнашучы турында сайлауга бәйле башка мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастыруга (урнаштыруга) ризалык, шулай ук шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык юллый.

14. Сайлап алуда катнашуга гаризалар кабул итү тәмамланганчы, сайлап алуда катнашучы сайлап алуда катнашуга яңа редакциядә гариза бирү юлы белән катнашуга үзгәрешләр кертергә хокуклы. Сайлауда катнашучы тарафыннан Вәкаләтле органга сайлап алуда катнашуга элек җибәрелгән гариза каралмый.

15. Комиссия утырышы көненә кадәр сайлап алуда катнашучы заказлы почта аша җибәреп яисә кулга тапшып юлланган язма гариза нигезендә сайлап алуда катнашуга гаризаны кире алырга хокуклы. Бу очракта гариза Комиссия утырышында карап тикшерелми. Гаризаны кире алу датасы булып вәкаләтле орган тарафыннан әлеге хәбәрнамәне теркәү көне тора.

16. Вәкаләтле орган сайлап алуны уздыру турындагы игъланда билгеләнгән сайлап алуны уздыру вакыты дәвамында гаризаларны, кабул итү көнен, вакытын күрсәтеп, алар килгән көнне терки һәм гаризалар кабул итү тәмамланганнан соң, 15 эш көненнән дә соңга калмыйча, аларны карау өчен Комиссиягә җибәрүне тәэмин итә.

Гаризалар кабул итү вакыты тәмамланганнан соң Вәкаләтле органга кергән гариза теркәлми.

Сайлап алуда катнашучылар тарафыннан тәкъдим ителгән гаризалар һәм беркетелгән документлар, сайлауда катнашучының язма гаризасы нигезендә гаризаларны кире алудан тыш, кире кайтарылмый.

Гаризалар бирү вакыты дәвамында бер генә гариза да тәкъдим ителмәгән очракта, сайлап алу узмаган дип таныла. Сайлап алуны узмаган дип тану турында мәгълүмат рәсми порталда гаризалар бирү вакыты тәмамланганнан соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

17. Вәкаләтле орган, сайлап алуда катнашуга гаризаларны кабул итү вакыты тәмамланган көннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, тиешле мөрәҗәгатьләр җибәрү юлы белән сайлап алучыларга карата түбәндәге документларны һәм мәгълүматны алуны тәэмин итә:

1) Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан яисә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Федераль салым хезмәтенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтыннан (https://nalog.ru) бастырып алына);

2) Банкротлык турында мәгълүматларның бердәм федераль реестрында сайлап алуда катнашучы турында мәгълүматлар булу (булмау) турында мәгълүмат (Банкротлык турында мәгълүматларның бердәм федераль реестрының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтыннан (https://fedresurs.ru) бастырып алына);

3) әлеге тәртипнең 18 пунктында күрсәтелгән Комиссия утырышы көненә кадәрге көнгә тәртиптә күрсәтелгән чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатлары өчен Казан шәһәренең башка норматив хокукый актлары нигезендә сайлап алуда катнашучының Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан акчалар алуы (алынмавы) турында мәгълүмат;

4) экстремистик эшчәнлеккә яисә терроризмга катнашы булулары турында белешмәләре булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә сайлап алуда катнашучы турында белешмәләрнең булуы (булмавы) хакында мәгълүмат (Финанс мониторингы буенча федераль хезмәтнең «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтының тиешле бүлегеннән бастырыла) https://www.fedsfm.ru);

5) «Чит ил йогынтысындагы затларның эшчәнлеген контрольдә тоту турында»гы федераль закон нигезендә чит ил агентлары реестрында сайлап алуда

катнашучы турында белешмәләрнең булуы (булмавы) турында мәгълүмат (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтыннан (https://minjust.gov.ru) бастырып алына );

6) БМО Уставының VII бүлеге, БМО Куркынычсызлык советы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кысаларында яки БМО Куркынычсызлык советы карарлары нигезендә махсус төзелгән оешмалар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән бәйле яисә массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә сайлап алуда катнашучы турында мәгълүматлар булу (булмау) хакында мәгълүмат (Финанс мониторингы буенча федераль хезмәтнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтындагы (https://www.fedsfm.ru) тиешле бүлегеннән бастырып алына).

18. Комиссия Вәкаләтле органнан әлеге тәртипнең 11 пунктында күрсәтелгән документларны алган көннән соң килүче көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә тапшырылган документларны карый һәм сайлап алу җиңүчеләрен билгеләү турында яисә гаризаны кире кагу турында карар кабул итә. Сайлап алу җиңүчеләрен билгеләү турындагы карар әлеге тәртипкә 3 номерлы кушымта нигезендә тәкъдимнәрне соратып алу беркетмәсе рәвешендә рәсмиләштерелә.

Субсидия бирү субсидия алуга гариза бирү көне һәм вакыты буенча чират тәртибендә гамәлгә ашырыла.

19. Комиссия, сайлап алуда җиңүчеләрне билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, рәсми порталда сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыра. Ул түбәндәге белешмәләрне үз эченә ала: гаризаларны карап тикшерүне уздыру көне, вакыты һәм урыны; гаризалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат; гаризаларны кире кагу сәбәпләрен, шул исәптән мондый гаризаларның сайлап алу уздыру турындагы игъланның кайсы нигезләмәләренә туры килмәвен күрсәтеп, гаризалары кире кагылган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат; сайлап алуда җиңүчеләрнең атамалары һәм аларга бирелә торган субсидия күләме.

20. Түбәндәге очраклар гаризаларны карап тикшерү стадиясендә аларны кире кагу өчен нигез булып тора:

- хокукый актта каралган сайлап алуны үткәрү турында игъланда күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

- конкурста катнашучы тарафыннан хокукый актта каралган тапшырылган

гаризаларның һәм (яисә) документларның сайлап алуны уздыру турындагы игъланда билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

- хокукый акт белән билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау максатыннан сайлауда катнашучы тапшырган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

- сайлап алуда катнашучының гариза бирү өчен билгеләнгән көннән һәм (яки) вакыттан соң гариза тапшыруы;

- сайлап алуда катнашучыларның әлеге тәртиптә күрсәтелгән критерийларга һәм таләпләргә туры килмәве;

- әлеге тәртипкә 2 пунктта күрсәтелгән максатларга субсидияләр бирү өчен Вәкаләтле органга билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән агымдагы финанс елына бюджет йөкләмәләре лимитлары бетүе;

- компенсация өчен билгеләнгән чыгымнарның субъект тарафыннан әлеге тәртиптә каралмаган максатларга тотылуы.

21. Вәкаләтле орган:

- субсидия алучыларга субсидия бирү турындагы комиссия карары нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат рәсми порталда урнаштырылган көннән алып календарь көннәрендә исәпләнә торган ун көн эчендә сайлап алуда җиңүче белән килешүне имзаларга тиеш;

- килешү Казан шәһәре Башкарма комитеты Финанс идарәсенең 2023 елның 12 гыйнварындагы 8 номерлы әмере белән билгеләнгән үрнәк форма нигезендә төзелә.

22. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

- субсидия бирүнең күләме, максаты, шартлары һәм тәртибе;

- субсидияне күчерү вакытлары;

- әлеге тәртиптә билгеләнгән шартлар бозылган очракта килешүне (шартнамәне) өзү тәртибе;

- бюджет акчаларын алучы буларак төп бүлүчегә килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкинлеге булмауга китерә торган итеп бюджет йөкләмәләренең элек җиткерелгән лимитлары кимetелгән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү яки, яңа шартлар буенча килештерүгә ирешелмәгәндә, килешүне өзү;

- субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап һәм субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләрне бирү тәртибе, вакыты һәм формалары;

- пассажир йөртүченең йөкләмәсе Вәкаләтле орган белән ул сатып алган автобусларны башка затларга милеккә бирүне һәм ул сатып алган автобусларга ия булу, алардан файдалану һәм алар белән эш итү хокукын тапшыруны килешү төзелгән көннән алып 5 ел дәвамында килештерү;

- әлеге тәртипнең 31 пунктында билгеләнгән субсидияләр бирү нәтиҗәсе кыйммәте;

- субсидия алучының, субсидияләр алучылар (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләрдән тыш) белән төзелгән килешүләр нигезендә акча алучы затларның аларга карата бюджет акчаларын баш бүлүче тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары тарафыннан тикшерүне гамәлгә ашыруга һәм мондый нигезләмәләрне килешүгә кертүгә ризалыгы;

- югары технологияле чит ил җиһазларын, чималын һәм комплектлаучы эшләнмәләрне сатып алганда (алар белән тәэмин иткәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән, шулай ук әлеге акчаларны бирү нәтиҗәләренә ирешү белән бәйле тәртип белән билгеләнгән башка операцияләрдән тыш, Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан алынган акча хисабына субсидия алучылар – юридик затлар, шулай ук субсидия алучылар белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы башка юридик затлар тарафыннан чит ил валютасы алуны тыю;

Кирәк булганда Вәкаләтле орган субсидия алучылар белән килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

23. Килешүне билгеләнгән вакытта имзаламаган сайлап алуда җиңүче Вәкаләтле орган карары белән килешү төзүдән баш тарткан дип таныла (карар субсидия алучы тарафыннан Килешү имзалау өчен вакыт узганнан соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча кабул ителә).

Вәкаләтле орган әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән алып 2 эш көне эчендә килешү төзүдән баш тарткан дип танылган сайлап алуда җиңүченең электрон почтасы адресы буенча, кире кагу сәбәбен күрсәтеп, аңа субсидия бирүне кире кагу турында хәбәрнамә җибәрә.

24. Юридик зат булган субсидияне алучыны кушу, кушылу яки үзгәртеп кору рәвешендә үзгәртеп оештырганда, килешүгә, хокуклар күчә торган юридик затны

килешүдә күрсәтеп, килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән йөкләмәдә затны алмаштыру өлешендә үзгәрешләр кертелә.

Юридик зат булган субсидия алучыны бүлү, бүлеп чыгару рәвешендә үзгәртеп оештырганда, шулай ук субсидия алучы юкка чыгарылганда яисә шәхси эшмәкәр булган субсидия алучының эшчәнлеге туктатылганда, берьяклы тәртиптә килешүне өзү турында хәбәрнамә һәм, субсидия алучы тарафыннан үтәлмәгән, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган йөкләмәләр һәм субсидиянең файдаланылмый калган өлешен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына кире кайтару турында мәгълүматны күрсәтеп, килешү буенча йөкләмәләрне үтәү турында акт формалаштырып, килешү өзелә.

25. Вәкаләтле орган субсидия бирү турында килешү имзаланган көннән алып 10 эш көне эчендә субсидия алучыларга Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетларына үзенең шәхси счетыннан акча күчерә.

26. Субсидия бирүдән баш тарту турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

- субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге тәртип белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки күрсәтелгән документларның (әлеге тәртипнең 11 пункты) тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

- субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы;

- оешманың әлеге тәртиптә билгеләнгән критерийларга туры килмәве;

- Казан шәһәре Думасының субсидия түләүгә бюджет турындагы карары белән каралган акчалар әлеге тәртип нигезендә субсидия буларак бирелгән очракта.

27. Субсидия күләме (P) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$P = \sum^{m} \text{N x Кавт}$$

биредә:

N – бер автобус өчен лизинг түләүләренең уртача айлык күләме, ул 390 000 000 сумга тигез, ләкин «Дәүләт транспорт лизинг компаниясе» акционерлык җәмгыяте белән 2024 елның 1 июленнән алып 2024 елның 31 декабренә кадәр төзелгән финанс белән бәйле арендалау (лизинг) килешүенә лизинг түләүләрен каплау графигы белән билгеләнгән айлык лизинг түләвенең күләменнән артмый;

Кавт – «Дәүләт транспорт лизинг компаниясе» акционерлык җәмгыяте белән 2024 елның 1 июленнән алып 2024 елның 31 декабренә кадәр төзелгән хәрәкәттәге

составны финанс белән бәйле арендалау (лизинг) килешүләре буенча лизингка алынган автобуслар саны;

m – субсидия алучы тарафыннан белдерелгән лизинг түләүләрен башкару айларының саны 3 айдан артмый.

28. Субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткече булып агымдагы елда пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашырганда транспорт хезмәте күрсәтүнең ышанычлылыгы тора, бу күрсәткеч кыйммәте >=0,7 булырга тиешле транспорт чараларын линиягә чыгару коэффициенты ярдәмендә бәяләнә.

Агымдагы елда линиягә транспорт чараларын чыгару коэффициенты ($К_{чыг}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$К_{чыг} = \sum Q_{фактчыгару} / \sum Q_{планчыгару},$$

биредә:

$Q_{фактчыгару}$ – «Дәүләт транспорт лизинг компаниясе» акционерлык җәмгыяте белән төзелгән финанс белән бәйле арендалау (лизинг) килешүләре буенча лизингка алынган автобусларны факт буенча линиягә чыгару;

$Q_{планчыгару}$ – Казан шәһәренең муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүгә муниципаль контрактлар нигезендә билгеләнгән «Дәүләт транспорт лизинг компаниясе» акционерлык җәмгыяте белән төзелгән финанс белән бәйле арендалау (лизинг) килешүләре буенча лизингка алынган автобусларны план буенча линиягә чыгару.

29. Субсидия алучы квартал саен хисап аеннан соң килүче айның бишенче көненә кадәр Вәкаләтле органга субсидия бирү турында килешүдә билгеләнгән форма буенча хәрәкәттәге составны (автобусларны) финанс белән бәйле арендалау (лизинг) килешүләре нигезендә лизинг түләүләрен башкаруга чыгымнарны (чыгымнарның бер өлешен) финанс белән тәэмин итүгә бүлеп бирелгән акчалардан файдалану турында хисап бирә.

30. Субсидияләр пассажир йөртүче Вәкаләтле орган белән ул сатып алган автобусларны башка затларга милеккә бирүне һәм ул сатып алган автобусларга ия булу, алардан файдалану һәм алар белән эш итү хокукын тапшыруны килешү төзелгән көннән алып 5 ел дәвамында килештерү йөкләмәләрен кабул иткән очракта бирелә.

31. Югары технологияле чит ил җиһазларын, чималын һәм комплектлаучы

эшләнмәләрне сатып алганда (алар белән тәэмин иткәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән, шулай ук әлеге акчаларны бирү нәтиҗәләренә ирешү белән бәйле тәртип белән билгеләнгән башка операцияләрдән тыш, Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан алынган акча хисабына субсидия алучыларга – юридик затларга, шулай ук субсидия алучылар белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы башка юридик затларга чит ил валютасы алу тыелган;

32. Субсидия алучылар, субсидияләр алучылар (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләрдән тыш) белән төзелгән килешүләр нигезендә акча алучы затлар аларга карата бюджет акчаларын баш бүлүче тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары тарафыннан тикшерүне гамәлгә ашыруга һәм мондый нигезләмәләрне килешүгә кертүгә ризалыгын бирергә тиеш;

33. Субсидия алучы Вәкаләтле органга билгеләнгән расписание нигезендә, хисап елыннан соң килүче елның 31 гыйнварыннан да соңга калмыйча, башкарылган рейсларның факттагы саны турында хисап тапшыра.

34. Россия Федерациясе законнары нигезендә Вәкаләтле орган тарафыннан субсидия алучыга карата субсидияләр бирү шартларын һәм тәртибен үтәү, шул исәптән аларны бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә тикшерү үткәрелә, муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан субсидия алучыларга карата Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә тикшерү үткәрелә.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча субсидияләр бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен бәяләү мөмкин булмаган очракта, урынга чыгып тикшерү үткәрелә. Субсидия алучы контроль өчен керү мөмкинлеген тәэмин итәргә, шулай ук күчмә тикшерү барышында субсидия бирүгә бәйле соралган документларны тапшырырга тиеш.

35. Вәкаләтле органга субсидияләр алучылар тарафыннан тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык субсидия алучының тиешле вазифаи затларына һәм җитәкчеләренә йөкләнә.

36. Субсидия алучы тарафыннан субсидияләр биргәндә билгеләнгән шартлар үтәлмәгәндә, шул исәптән шартларның үтәлмәве Вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс

контроле органы үткәргән тикшерү фактлары буенча ачыкланган очракта, бирелгән субсидия Вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән алып утыз эш көне эчендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты кеременә тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш.

37. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты кеременә акчаларны үз теләге белән кире кайтарудан баш тарткан очракта, алар Вәкаләтле орган тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә 30 көн эчендә мәҗбүри тәртиптә түләттерелергә тиеш.

38. Субсидия акчаларын максатчан һәм нәтиҗәле файдаланган, шулай ук субсидия алу максатыннан тапшырылган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә субсидия алучыга йөкләнә.

39. Бюджет акчаларыннан файдалануны Вәкаләтле орган контрольдә тота.

___________________

Хәрәкәттәге составны (автобусларны) финанс белән бәйле арендалау (лизинг) килешүләре нигезендә лизинг түләүләрен башкаруга чыгымнарны (чыгымнарның бер өлешен) финанс белән тәэмин итү өчен шәһәр автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашыра торган юридик затларга һәм (яисә) шәхси эшмәкәрләргә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетынан субсидияләр бирү тәртибенә 1 номерлы кушымта
(Форма)

**Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр алу өчен сайлап алуда катнашуга гариза**

Субсидия атамасы: ________________________________________

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Гариза бирүче (сайлап алуда катнашучының тулы һәм кыскартылган исеме; шәхси эшмәкәр өчен – фамилиясе, исеме, атасының исеме) | |
| 2 | Төп дәүләт теркәве номеры (ОГРН) | |
| 3 | Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН) | |
| 4 | Салым органында исәпкә кую вакыты (шәхси эшмәкәр өчен), салым органында исәпкә кую вакыты һәм сәбәбенең коды (юридик затлар өчен) | |
| 5 | Физик затны шәхси эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алу көне | |
| 6 | Туган көне һәм урыны (шәхси эшмәкәр өчен) | |
| 7 | Аерым шәхси счетның иминият номеры (шәхси эшмәкәр өчен) | |
| 8 | Юридик затның адресы, теркәлү адресы (шәхси эшмәкәр өчен) | |

| | | |
|---|---|---|
| 9 | Телефон | |
| 10 | Почта адресы һәм электрон почта адресы | |
| 11 | Җитәкче (фамилиясе, исеме, атасының исеме, салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН), вазифасы) | |
| 12 | Вәкаләтләрне раслый торган документ (исеме, көне, номеры) | |
| 13 | Баш бухгалтер (фамилиясе, исеме, атасының исеме, салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН)) (булган очракта) | |
| 14 | Төп һәм өстәмә эшчәнлек төрләре (Икътисади эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторы (ОКВЭД)) | |
| 15 | Субсидия күләме, сумнарда | |
| 16 | Хисап чоры | |
| 17 | Хезмәт күрсәтү урыны (адресы) | |
| 18 | Әлеге гариза белән гариза нигезендә сайлап алуга бәйле мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгымны белдерәм<br>______________________<br>(имза) | |
| 19 | Субсидия алу өчен сайлап алуда катнашу мөмкинлеге бирә торган дөрес булмаган белешмәләр тапшырган өчен Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә җаваплылык каралган булуы турында әлеге гариза белән хәбәр ителде<br>__________<br>(имза) | |
| 20 | Әлеге гариза белән түбәндәгеләрнең булмавын раслыйм:<br>- салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар һәм процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурыч;<br>- Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча түләү вакыты узган бурыч һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына түләү вакыты узган башка бурыч<br>_____________<br>(имза) | |
| 21 | Сайлап алуны уздыру шартлары белән таныштым һәм, тәртипкә нигезләнеп, түбәндәге исемлек буенча кирәкле документларны тапшырам | |

| | | |
|---|---|---|
| 22 | Гаризага беркетәм: | |
| | 1. | ___ биттә |
| | 2. | ___ биттә |
| | 3. | ___ биттә |
| | 4. | ___ биттә |

______________________________________________________________________________

(имзасы, вазифасының атамасы, фамилиясе һәм инициаллары)

Гариза бирү вакыты: «____» ____________ 20___ ел

Хәрәкәттәге составны (автобусларны) финанс белән бәйле арендалау (лизинг) килешүләре нигезендә лизинг түләүләрен башкаруга чыгымнарны (чыгымнарның бер өлешен) финанс белән тәэмин итү өчен шәһәр автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашыра торган юридик затларга һәм (яисә) шәхси эшмәкәрләргә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетынан субсидияләр бирү тәртибенә 2 номерлы кушымта
(Форма)

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык

Мин, ______________________________________________________________,
(шәхси мәгълүматлар субъектының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))
_________________________________________________ адресы буенча теркәлгән,
паспорт: сериясе ______ номеры __________«____» _______________ бирелгән
(бирелү вакыты)
___________________________________________________________________________,
(документны биргән органның атамасы)
___________________________________________________________________________,
(шәхси мәгълүматлар субъекты вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))
_________________________________________________ адресы буенча теркәлгән,
паспорт: сериясе ______ номеры __________«____» _______________ бирелгән
(бирелү вакыты)
___________________________________________________________________________,
(документны биргән органның атамасы)
___________________________________________________________________________,
[ышаныч кәгазе яки әлеге вәкилнең вәкаләтләрен раслый торган башка документ реквизитлары (шәхси мәгълүматлар субъекты вәкиленнән ризалык алганда)]

2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законның 9 статьясы нигезендә үз ихтыярым белән һәм үз мәнфәгатьләремдә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчесенә субсидия бирү турындагы килешүне төзү һәм үтәү максатыннан операторга ____________________________ автоматлаштырылган, шулай ук автоматлаштыру чараларын кулланмыйча, шәхси мәгълүматларны җыю, язу, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау

(яңарту, үзгәртү), чыгару, куллану, тапшыру (тарату, бирү, куллануга рөхсәт бирү), шәхси үзенчәлекләрен бетерү, вакытлыча тыю, бетерү, юкка чыгаруны кертеп, минем шәхси мәгълүматларымны, аерым алганда түбәндәгеләрне (алга таба кирәклесенең астына сызарга) эшкәртүгә ризалык бирәм:

1) гражданинның фамилиясе, исеме яки атасының исеме үзгәрү турындагы белешмәләрне дә кертеп, анкета мәгълүматларын, яшәү урыны адресын (теркәлү буенча һәм факттагы), электрон почта адресын һәм телефон номерын;

2) сериясен, номерын, бирелү датасын, документ биргән органның атамасын кертеп, паспорт мәгълүматларын яисә шәхесне һәм гражданлыкны таныклый торган башка документ мәгълүматларын;

3) салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры турында мәгълүматларны;

4) салым органында исәпкә кую турында мәгълүматларны;

5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булмау турында мәгълүматларны;

6) бюджеттан тыш фондларга иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар буенча бурычлар булу (булмау) турында мәгълүматларны;

7) кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетлары турында мәгълүматларны.

Әгәр минем шәхси мәгълүматларымны өченче як аша гына алырга мөмкин булса, миңа бу хакта шәхси мәгълүматларны алу максатларын, күздә тотылган чыганакларын һәм алу ысулларын күрсәтеп алдан хәбәр ителергә, шулай ук моңа ризалык алынган булырга тиеш.

Шәхси мәгълүматларымны эшкәртү белән бәйле хокукларым һәм бурычларым, шул исәптән, шәхси мәгълүматларым үзгәргән очракта, бу хакта операторга хәбәр итәргә тиешлегем; операторга тиешле язмача гариза юллап, үз ризалыгымны теләсә кайсы вакытта кайтарып алырга хокуклы булуым турында миңа аңлатылды.

Ризалык аңа имза куелган көннән гамәлгә керә һәм шәхси мәгълүматларны эшкәртүнең максатына ирешкәнче яки язма формада ризалыкны кире алганчы, билгесез вакыт дәвамында гамәлдә була.

____________________________________________________________

(имза, фамилия һәм инициаллар)

Ризалык бирү көне: «____» ____________ 20___ ел.

Хәрәкәттәге составны (автобусларны) финанс белән бәйле арендалау (лизинг) килешүләре нигезендә лизинг түләүләрен башкаруга чыгымнарны (чыгымнарның бер өлешен) финанс белән тәэмин итү өчен шәһәр автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашыра торган юридик затларга һәм (яисә) шәхси эшмәкәрләргә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә
3 номерлы кушымта
(Форма)

**_____ номерлы сайлап алу нәтиҗәләрен чыгару беркетмәсе**

______ елның _________________ Казан шәһәре

1. Сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (гаризаларын) карап тикшерүне уздыру көне, вакыты һәм урыны: ________________________________.

2. Комиссиядә катнашучы әгъзалар:

| Вазифаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме | Вазифасы |
|---|---|
| | |

Карар кабул итү өчен кворум бар.

3. Сайлап алуда катнашучы түбәндәге затлардан тәкъдимнәр (гаризалар) алынды:

1) _________________________________________________________________;

2) _________________________________________________________________.

4. Тәкъдимнәре (гаризалары) кире кагылган сайлап алуда катнашучылар турында кире кагылу сәбәпләре, шул исәптән сайлап алу үткәрү турында игъланның мондый тәкъдимнәр (гаризалар) туры килми торган нигезләмәләре күрсәтелгән мәгълүмат:

| Сайлап алуда катнашучының исеме | Тәкъдимне (гаризаны) кире кагу өчен нигезләр |
|---|---|
| | |
| | |

5. Субсидия бирү турында килешү төзелә торган субсидия алучының (алучыларның) исеме һәм аңа (аларга) бирелә торган субсидия күләме: ___________________________________________________________________________

Комиссия әгъзаларының имзалары:

_______________________________

_______________________________

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 9 ноябрендәге
4692 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**Хәрәкәттәге составны (автобусларны) финанс белән бәйле арендалау (лизинг) килешүләре нигезендә лизинг түләүләрен башкаруга чыгымнарны (чыгымнарның бер өлешен) финанс белән тәэмин итү өчен шәһәр автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашыра торган юридик затларга һәм (яисә) шәхси эшмәкәрләргә субсидияләр бирү комиссиясе турында нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә хәрәкәттәге составны (автобусларны) финанс белән бәйле арендалау (лизинг) килешүләре нигезендә лизинг түләүләрен башкаруга чыгымнарны (чыгымнарның бер өлешен) финанс белән тәэмин итү өчен шәһәр автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашыра торган юридик затларга һәм (яисә) шәхси эшмәкәрләргә субсидияләр бирү комиссиянең (алга таба – Комиссия) эш тәртибен билгели.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституция законнарына, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка хокукый актларына, Татарстан Республикасы хокукый актларына, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Комиссия субсидия алуга дәгъва кыла торган юридик затларны һәм (яисә) шәхси эшмәкәрләрне сайлап алу процедурасын гамәлгә ашыра, шул исәптән:

- шәһәрдә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыра торган юридик затларның һәм (яисә) шәхси эшмәкәрләрнең субсидия алуга гаризаларын Хәрәкәттәге составны (автобусларны) финанс белән бәйле арендалау (лизинг) килешүләре нигезендә лизинг түләүләрен башкаруга чыгымнарны (чыгымнарның бер өлешен) финанс белән тәэмин итү өчен шәһәрдә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыра торган юридик затларга һәм (яисә) шәхси эшмәкәрләргә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе (алга таба – Тәртип) һәм әлеге Нигезләмә буенча карап тикшерә;

- сайлап алу җиңүчеләрен билгеләү турында яки гаризаларны кире кагу

турында карар кабул итә.

4. Вәкаләтле орган тарафыннан тапшырылган гаризаларны карап тикшерү һәм бәяләү комиссия әгъзалары тарафыннан утырышта бәйсез һәм шәхси рәвештә гамәлгә ашырыла.

5. Комиссия эшчәнлеген оештыруны һәм техник яктан тәэмин итүне Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитеты башкара.

6. Комиссия составына Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, Комиссия сәркатибе, Комиссиянең башка әгъзалары керә.

7. Комиссия рәисе:

7.1. Комиссия эшчәнлеге белән гомуми җитәкчелек итүне башкара;

7.2. Комиссия утырышларын җыя һәм алып бара;

7.3. Комиссия бәяләмәсен раслый һәм имзалый;

7.4. кирәк булган очракта, Комиссия утырышын уздыруны Комиссия рәисе урынбасарына йөкли;

7.5. Комиссия әгъзаларына Комиссия эшчәнлеге белән бәйле булган телдән һәм язма йөкләмәләр бирә;

7.6. Комиссиянең тиешенчә эшләвен оештыру өчен кирәк булган башка вәкаләтләрне башкара.

8. Комиссия рәисе урынбасары ул булмаган очракта Комиссия рәисе функцияләрен үти.

9. Комиссия сәркатибе:

9.1. Комиссия утырышларына эш материалларын әзерләүне оештыра;

9.2. Комиссия утырышларын оештыра, Комиссия әгъзаларына Комиссия утырышын уздыру вакыты һәм урыны турында хәбәр итә;

9.3. Комиссия утырышлары беркетмәләрен алып бара;

9.4. Комиссия бәяләмәләре проектларын әзерли.

10. Комиссия әгъзалары аның утырышларында шәхсән катнаша. Комиссия әгъзасы булмаган очракта, комиссия эшендә аның вазифаларын вакытлыча башкаручы катнаша.

11. Комиссия, расланган Тәртипкә таянып, сайлап алу критерийлары һәм кагыйдәләре нигезендә субсидия бирү яки субсидия бирүне кире кагу турында карар кабул итә.

Гаризаларны карап тикшерү һәм бәяләү нәтиҗәләре сайлап алуны йомгаклау беркетмәсенә (Тәртипкә 3 номерлы кушымта) кертелә, ул Комиссиянең барлык әгъзалары һәм Комиссия рәисе тарафыннан имзалана.

______________________

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 9 ноябрендәге
4692 номерлы карарына
3 номерлы кушымта

**Хәрәкәттәге составны (автобусларны) финанс белән бәйле арендалау (лизинг) килешүләре нигезендә лизинг түләүләрен башкаруга чыгымнарны (чыгымнарның бер өлешен) финанс белән тәэмин итү өчен шәһәр автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашыра торган юридик затларга һәм (яисә) шәхси эшмәкәрләргә субсидияләр бирү комиссиясе составы**

Комиссия рәисе – Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең транспорт, икътисади үсеш һәм сәүдә мәсьәләләре буенча урынбасары.

Комиссия рәисе урынбасары – Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитеты рәисе.

Комиссия сәркатибе – Казан шәһәре Башкарма комитеты Транспорт комитетының финанс бүлеге башлыгы.

Комиссия әгъзалары:

- Казан шәһәре Башкарма комитеты Транспорт комитеты рәисенең икътисад мәсьәләләре өчен җаваплы урынбасары;
- Казан шәһәре Башкарма комитеты Транспорт комитеты рәисенең автомобиль, җир өсте электр транспорты, метрополитен эше мәсьәләләре буенча җаваплы урынбасары;
- Казан шәһәре Башкарма комитеты Транспорт комитетының автомобиль транспорты бүлеге башлыгы;
- Казан шәһәре Башкарма комитеты Транспорт комитетының метрополитен һәм җир өсте электр транспорты бүлеге башлыгы;
- Казан шәһәре Башкарма комитеты Транспорт комитетының шәһәр пассажир транспортын үстерү программалары бүлеге башлыгы.

Искәрмә. Комиссия әгъзалары комиссия утырышларында шәхсән катнаша. Комиссия әгъзасы булмаган очракта, комиссия эшендә аның вазифаларын вакытлыча башкаручы катнаша.

---